Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № № XIII-6**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 16 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8, 8.1, 12.1 маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге 7.1 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакындагы, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-4 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Объектив сәбәпләр аркасында муниципаль хезмәткәрләргә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта әлеге факт муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын (каршылыгын, низагын) җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында каралырга тиеш.»;

2. «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакындагы, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-5 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынына дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган керемнәре мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук муниципаль район Башлыгы, район Башлыгы урынбасары вазыйфаларын башкаручы затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә тапшырыла (алга таба – район Башкарма комитетының оештыру бүлеге).

Район Советы депутатының (район Башлыгы, район Башлыгы урынбасарыннан кала) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының оештыру бүлегенә тапшырыла (алга таба – район Советы аппаратының оештыру бүлеге).»;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта әлеге факт муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында каралырга тиеш..»;

в) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Вазыйфаи бурычларына әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган мәгълүматлар белән эшләү керә торган район Башкарма комитетының оештыру бүлеге, район Советы Аппаратының оештыру бүлеге затлары арасыннан муниципаль хезмәткәрләр, бу мәгълүматларны фаш итүдә яисә законнарда каралмаган максатларда файдалануда гаепле затлар, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүматларны фаш итүдә гаепле затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.»;

3. Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар урнаштыру тәртибе турында һәм аларны бастырып чыгару өчен гаммәви мәгълүмат чараларына шушы мәгълүматларны бирү тәртибе хакындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-6 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларны рәсми сайтка урнаштыру муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары бүлекчәләре тарафыннан тәэмин ителә (алга таба - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре).

Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән район Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, район Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны рәсми сайтта урнаштыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге белән тәэмин ителә (алга таба – район Башкарма комитетының оештыру бүлеге).

Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән район Советы депутатының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан күрсәтелгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны рәсми сайтта урнаштыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге тарафыннан тәэмин ителә (алга таба – район Советы аппаратының оештыру бүлеге).»;

б) 6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының район Советы аппаратының оештыру бүлеге, җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәте, шул исәптән район Башкарма комитетының оештыру бүлеге:»;

в) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләрендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр, шул исәптән район Башкарма комитетының оештыру бүлегендә, шулай ук район Советы аппаратының оештыру бүлегендә, массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге Нигезләмә нигезендә урнаштыруны һәм аларга мәгълүматлар тапшыруны тәэмин итүче муниципаль хезмәткәрләр әлеге Нигезләмәне үтәмәгән, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүматларны фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.»;

4. Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан хәбәр итү тәртибе хакындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-11 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль район Башлыгы, муниципаль район Советы рәисе, муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе, муниципаль районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, муниципаль районның финанс-бюджет

палатасы рәисе адресына кергән мөрәҗәгатьләр муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә тапшырыла (алга таба – Комиссия).»;

б) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән расланган Комиссия турында Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә хәбәрнамәләрне карый һәм алар буенча карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны муниципаль район Башлыгына, муниципаль район Советы рәисенә, муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенә, муниципаль районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә яисә муниципаль районның Финанс-бюджет палатасы рәисенә юллый.»

в) Нигезләмәгә 1 нче кушымтада «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре» сүзләренә алмаштырырга;

г) Нигезләмәгә 2 нче кушымтада «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) Нигезләмәгә 3 нче кушымтада «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре» сүзләренә алмаштырырга.

5. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы рәсми сайтының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2016 елның 23 апрелендәге Х-12 номерлы карары белән расланган Таләпләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «II. “Коррупциягә каршы тору” бүлеге мәгълүматын тулыландыруга таләпләр» бүлегендә:

1 пунктның сигезенче абзацында «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү,

муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктта «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфа тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия» сүзләренә алмаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев